

Румия Юнер кызы Иштрякова сигез елдан артык Кадошкино поликлиника бvлегендә процедура кабинетын житәкли.
- Шәфкать туташы булуыма vкенмим, -ди Румия Юнеровна.
Шәфкать туташы булу – ул бер нәрсә, ә процедура кабинеты шәфкать туташы булу – икенче. Зур тvземлелек, торле пациентлар белән эш итәргә кvп осталык сорала, чонки һәрбер авыру vзенә игътибарлылыкнын зурысын, белемнен – әйбәтен vзендә тоярга тели. Коненә 70кә кадәр кан алу процедурасы vтә икән Румия Юнер кызы кулы аша. Килгән пациентларны иртәгә калдырырга ярамый бит! Кыенлыгы - аерым (специализированный) бvлек булмавы. Остәвенә биредә канны остәмә тикшерv vткәрv очен дә алына. Конечно, кем бу профессияне сайлый, башкача булдыра да алмый; vзендә барлык унай якларны гына туплаган шәфкать туташы гына хезмәтен тиешенчә vткәрә ала.
Бу профессия шәфкатьлелек, яхшылык һәм ярдәмчелек таләп итә.       – Шәфкать туташы профессиясен мин теләп vзләштердем, - ди Румия Юнер кызы. – Урта мәктәпне тәмамлап  тормыйча, Казан  шәһәренә белем алырга дип юл тоттым. Анда медицина училищесына укырга кердем. Апамда яшәргә туры килде. Ул минем беренче укытучым, остазым да булды. Шул вакыт апам шәһәр шифаханәсендә терапевт булып хезмәт итә иде. Профессиямнен нечкәлекләренә анардан ойрәндем дә инде. Мин бервакытта да шундый профессия сайлавыма vкенмәдем һәм vкенмим дә.Һәрвакыт кешеләргә ярдәм итv теләге шуна сәбәп булгандыр да инде.
Казанда укуны тәмамлагач, Румия Иштрякова башта медсанчастьтә эшли, соныннан – шәһәр шифаханәсендә. Ә туган ягына якыннарын кvрергә дип кайткан очракнын сонгысында,  язмышым аны, тормыш иптәше белән Таджикистанга юллады. Анда ул чикле кvрvче балалар мәктәп-интернатына хезмәткә урнаша. Бәлкем, шул факт профессиясенә тагы да бәйләгәндер vзен. Ул бу оешмалар башка кvзлек астыннан доньяга, профессиягә карарга мәжбур итә дип саный.
Коллегалары аны vз вазифасына зур жаваплылык белән караганы, ярдәмчеллегенә, тормышка оптимистик караштa булуына яраталар, хормәт итәләр. Анын молаем елмаюы, кеше хәленә кереп, кирәккәндә жылы сvз таба белvе пациентларына дәвалану

процессындагы авырлыкларны жинел vтәргә ярдәм итә. Ә бит медицина хезмәткәренен елмаюы - дару, ягымлы сvзе – шифа. Шундый булып калу очен, эштән арып кайткан чакларда хобби – чәчәкләре белән шогыльләнә Румия ханым. Алар бар киеренкелекне югалта, коч ости; ак халатлы шәфкать иясе булып калырга ярдәм итә.

**Н.Хәлил**